**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Азалак авылы торак пунктында 2025 елда үзара салым кертү турында

2024 елның 11 нче ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Азалак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Азалак авылы торак пунктында "I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

- Азалак авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

2. Азалак торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Азалак авылында Елга урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү).

3. Коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

- коены ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

4. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:

- чишмәне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

- Азалак авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу;
– язгы ташу вакытында торак пункт территориясен су басудан саклау өчен җир өеме ясау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

6. махсус күмү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү, коймалар кору:
-язгы ташу вакытында зират территориясен су басудан саклау өчен җир өеме ясау (махсус техника арендалау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
7. Санкциясез чүплекләрне бетерү:
- Азалак авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);
3. Әлеге карарны Азалак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Г.Габдулгазизов